КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 20 июль г.Казань № 608

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджетыннан юридик затларга мәгариф һәм фән өлкәсендә чаралар (конференцияләр, киңәшмәләр, олимпиадалар, симпозиумнар, съездлар, белем бирү сменалары, күргәзмәләр, конкурслар, һөнәри осталык чемпионатлары, шулай ук бүтән чаралар) оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә (каплауга) субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 28 март, 197 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджетыннан юридик затларга мәгариф һәм фән өлкәсендә чаралар (конференцияләр, киңәшмәләр, олимпиадалар, симпозиумнар, съездлар, белем бирү сменалары, күргәзмәләр, конкурслар, һөнәри осталык чемпионатлары, шулай ук бүтән чаралар) оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә (каплауга) субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 28 март, 197 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 27 ноябрь, 1061 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче пунктта «мәгариф һәм фән өлкәсендә» сүзләре алдына «, мәгариф һәм фән өлкәсендә чаралар үткәргәндә кулланыла торган җиһазларның сакланышын тәэмин итеп,» сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы бюджетыннан юридик затларга мәгариф һәм фән өлкәсендә чаралар (конференцияләр, киңәшмәләр, олимпиадалар, симпозиумнар, съездлар, белем бирү сменалары, күргәзмәләр, конкурслар, һөнәри осталык чемпионатлары, шулай ук бүтән чаралар) оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә (каплауга) субсидияләр бирү тәртибендә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы бюджетыннан юридик затларга, мәгариф һәм фән өлкәсендә чаралар үткәргәндә кулланыла торган җиһазларның сакланышын тәэмин итеп, мәгариф һәм фән өлкәсендә чаралар (конференцияләр, киңәшмәләр, олимпиадалар, симпозиумнар, съездлар, белем бирү сменалары, күргәзмәләр, конкурслар, һөнәри осталык чемпионатлары, шулай ук бүтән чаралар) оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә (каплауга) субсидияләр бирү тәртибе»;

1 нче пунктта «мәгариф һәм фән өлкәсендә» сүзләре алдына «, мәгариф һәм фән өлкәсендә чаралар үткәргәндә кулланыла торган җиһазларның сакланышын тәэмин итеп,» сүзләрен өстәргә;

2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Субсидияләр юридик затларга мәгариф һәм фән өлкәсендә чаралар үткәргәндә кулланыла торган җиһазларның сакланышын тәэмин итеп, мәгариф һәм фән өлкәсендә чаралар (конференцияләр, киңәшмәләр, олимпиадалар, симпозиумнар, съездлар, белем бирү сменалары, күргәзмәләр, конкурслар, һөнәри осталык чемпионатлары, шулай ук бүтән чаралар) (алга таба – чаралар) оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү (каплау) максатларында бирелә.»;

3 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Бюджет акчасын алучы буларак аңа тиешле финанс елына субсидия бирүгә бюджет йөкләмәләре лимитлары Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче булып Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы (алга таба – вәкаләтле орган) тора.»;

4 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Субсидия бирүгә бюджет йөкләмәләре лимитлары җитмәүгә бәйле рәвештә, агымдагы финанс елында субсидия бирү мөмкинлеге булмаган очракта, субсидия бу Тәртипнең 5 нче пунктында күрсәтелгән сайлап алу критерийларына туры килүче субсидия алучыга чираттагы финанс елында әлеге сайлап алу критерийларына туры килү-килмәүгә яңадан тикшерү үткәрелмичә бирелә.»;

5 нче пунктта:

беренче абзацка «түбәндәге шартларга» сүзләреннән соң «һәм таләпләргә» сүзләрен өстәргә;

җиденче абзацта татар текстында «яки банкротлык» сүзләрен төшереп калдырырга, «һәм» сүзе алдына «, аларга карата банкротлык процедурасы

билгеләнмәгән, субсидия алучының эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган тәртиптә туктатылмаган» сүзләрен өстәргә;

6 нчы пунктта:

җиденче абзацта татар текстында «яки банкротлык» сүзләрен төшереп калдырырга, «һәм» сүзе алдына «, аларга карата банкротлык процедурасы билгеләнмәвен, субсидия алучының эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган тәртиптә туктатылмавын» сүзләрен өстәргә;

унөченче абзацта «Россия Банкының «Саф акчага исәп-хисапларны гамәлгә ашыру турында» 2013 елның 7 октябрендәге 3073-У номерлы күрсәтмәсен» сүзләрен «Россия Банкының «Саф акчага исәп-хисаплар ясау кагыйдәләре турында» 2019 елның 9 декабрендәге 5348-У номерлы күрсәтмәсен» сүзләренә алыштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«мәгариф өлкәсендә чара үткәргәндә кулланыла торган, сакланышын тәэмин итәргә кирәк булган җиһазлар исемлеген;

мәгариф өлкәсендә чаралар үткәргәндә кулланыла торган җиһазларның сакланышын тәэмин итүгә чыгымнар сметасын.»;

12 нче пунктта:

икенче абзацта «нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» сүзләрен «нәтиҗәләре» сүзенә алыштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Субсидия бирү турындагы килешүдә бюджет акчасын алучы буларак вәкаләтле органның субсидия алучы тарафыннан өстәмә хисаплылык бирү вакытларын һәм формаларын билгеләү хокукы күздә тотыла.»;

$12^1$ нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$12^1$. Мәгариф өлкәсендә чаралар оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү (каплау) максатларында субсидия бирү нәтиҗәләре түбәндәгеләр була:

чара үткәрү вакытларын үтәү,

чара үткәрү максатларына ирешү.

Мәгариф өлкәсендә чаралар үткәргәндә кулланыла торган җиһазларның сакланышын тәэмин итүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү (каплау) максатларында субсидия бирү нәтиҗәсе булып җиһазларны, табигый (амортизация) тузуын исәпкә алып, субсидия алучыга тапшырылган торышта саклау тора.»;

14 нче пунктта:

беренче абзацта «Субсидия күләме» сүзләрен «Субсидия күләме (S)» сүзләренә алыштырырга;

дүртенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«E – чара оештыруга һәм үткәрүгә һәм (яки) чара үткәргәндә кулланыла торган җиһазларның сакланышын тәэмин итүгә фактта тотылган чыгымнар.»;

15 нче пунктта «кредит оешмаларында» сүзләрен «Россия кредит оешмаларында» сүзләренә алыштырырга;

17 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17. Субсидияләр алучылар вәкаләтле органга, агымдагы елның 15 декабреннән дә соңга калмыйча, кәгазь чыганакта вәкаләтле зат тарафыннан имзаланган субсидиядән файдалану турында хисап, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында хисап тапшыра.

Субсидиядән файдалану турында хисап һәм субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турында хисап бу Тәртипкә теркәлгән кушымтада бирелгән форма буенча кертелә.»;

Тәртипкә кушымта (карарга теркәлә) өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы бюджетыннан юридик затларга мәгариф һәм фән өлкәсендә чаралар (конференцияләр, киңәшмәләр, олимпиадалар, симпозиумнар, съездлар, белем бирү сменалары, күргәзмәләр, конкурслар, һөнәри осталык чемпионатлары, шулай ук бүтән чаралар) оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә (каплауга) субсидияләр бирү тәртибенә
кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 20 июль, 608 нче
карары редакциясендә)

Форма

20___ елның «___»_________ __ хәленә карата субсидиядән файдалану турында
ХИСАП

Юридик затның исеме: ________________________________________________
Тапшыру вакыты: ____________________________________________________

| Субсидия чараларыннан файдалану юнәлеше* | Чыгымнарны функциональ классификацияләү коды | | | | Чыгымнарны икътисадый классификацияләү коды | Ел башыннан акча керде | Ел башыннан акча тотылды |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | бүлек | бүлекчә | максатчан статья | чыгым төре | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| | | | | | | | |

* Хисапка беренчел бухгалтерлык исәбе документларының күчермәләре теркәлә.

Юридик затның җитәкчесе (вәкаләтле зат) ____________ ____________ ____________________
(вазыйфасы) (имзасы) (фамилиясе, инициаллары)

20__ ел, «__» ________

Субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турында
ХИСАП

Юридик затның исеме: ____________________________________________________________
Тапшыру вакыты: ________________________________________________________________

| Т/с | Нәтиҗә исеме | Гомумроссия үлчәү берәмлекләре классификаторы буенча үлчәү берәмлеге | | Нәтиҗәнең план буенча мәгънәсе | Хисап көне хәленә карата нәтиҗәнең ирешелгән мәгънәсе | Планны үтәү проценты | Тайпылу сәбәбе |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | исеме | коды | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| | | | | | | | |

Юридик затның җитәкчесе (вәкаләтле зат) ____________ ____________ ____________________
(вазыйфасы) (имзасы) (фамилиясе, инициаллары)

20__ ел, «__» ________

_______________________________________